**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Яңа Шашы авыл җирлеге Иске Җогып торак пунктында**

# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

"28" ноябрь 2019 ел. № 2

2003 елның 6 октябрендәге 131-Фз номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлегенең Иске Җогып торак пунктында халык җыены

КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге Иске Җогып авылы территориясендә 2021 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлегенең Иске Җогып авыл җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:

1) Җирлек территориясен төзекләндерү һәм чистарту:
- Иске Җогып авылында чишмә ремонтына төзү материаллары алу һәм эш өчен түләү;

2) авыл җирлеге территориясендә җирле әһәмияттәге урам юлларына карата юл эшчәнлеге:
- Иске Җогып авылында юлларны төзекләндерүгә вак таш алу һәм транспорт хезмәте өчен түләү.

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлегенең Иске Җогып авылында яшәүче халык җыенының әлеге карарын Яңа Шашы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4 Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге Иске Җогып авылында узган халык җыены карарын Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Яңа Шашы авыл җирлеге башлыгы Сабирҗанов М.С.

Совет Новошашинского сельского поселения
Яңа Шашы авыл җирлеге Советы